СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 350 от 29.04.2020
на № __от ________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 308 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең бюджет законнары үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2019 елныц 23 октябрендәге 308 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"14 Статья Муниципаль заказ

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү очен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елныц 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль заказ район бюджеты акчалары хисабына түләнә".

**1.2.** 16 статьяныц ундүртенче абзацында "акчаларны исәпкә алу буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.3.** 16 статьяныц уналтынчы абзацын үз кочен югалткан дип танырга;

**1.4.** 23 статьяныц 2 пунктында "һәм үтәләләр" сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.5.** 28 статьяныц 4 пунктында "һәм үтәлә" сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.6.** 28 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия белән фәкать акцияләренец (өлешләренең) 100 проценты районга (гарантка) карый торган хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре, молкәте район (гарант) милкендә булган муниципаль унитар предприятиенең йөкләмәләре генә тәэмин ителергә мөмкин.”;

**1.7.** 28 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакцниядә бәян итәргә:

“11. Кредит (заем, шул исәптән облигация) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия, муниципаль гарантиядә күрсәтелгән, гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган топ йокләмәләр шартлары гарантныц алдан язма ризалыгыннан башка үзгәргән очракта һәм (яисә) аңа карата Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитор тарафыннан кредит акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту гамәлгә ашырыла торган муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (заем, шул исәптән облигация) чараларын максатсыз файдалану очрагында гына, гарант тарафыннан чакыртып алынырга тиеш”;

**1.8.** 28 статьяныц 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

**1.9.** 36 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Бюджет проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

– Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган нигезләмәләре;

– Россия Федерациясе Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре, Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенец төп юнәлешләре, бюджет һәм салым сәясәтенең топ юнәлешләре;

– социаль-икътисадый үсеш фаразы;

– озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты) ;

– дәүләт һәм мунициапль программалар, дәүләт һәм муниципаль программалар проектлары, әлеге программаларга үзгәрешләр кертү проектлары.”;

**1.10.** 41 статьяның 2 пунктындагы 3 абзацында “ике” сүзен “өч” сүзенә алмаштырырга;

**1.11**. 48 статьяныц бишенче абзацында “салымнар һәм җыемнар турында” сүзләрен тошереп калдырырга;

**1.12.** 49 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында “бюджет йокләмәләре” сүзләрен “һәм бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне исәпкә алу” сүзләренә алмаштырырга;

**1.13.** 49 статьяның 3 пунктында “түләү һәм” сүзләрен “казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр һәм” сүзләренә алмаштырырга (алга таба - күрсәтмә).;

**1.14.** 49 статьяның 5 пунктында “түләү документлары” сүзләрен “күрсәтмәләр” сүзенә алмаштырырга;

**1.15.** 50 статьяның 3 пунктында “чыгымнар буенча” сүзләреннән сон “һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары” сүзләрен өстәргә;

**1.16.** 50 статьяның 4 пунктында “чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары, шулай ук дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча күрсәткечләрнең бюджет язмасы” сүзләрен “чыгымнар торләре төркемнәре (төркемчәләре һәм элементлары) буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары” сүзләренә алмаштырырга;

**1.17.** 53 статьяның 1 пунктында “һәм стандартлар” сүзләрен төшереп калдырырга, “билгеләнәләр” сүзен “билгеләнә” сүзе белән алмаштырырга;

**1.18.** 56 статьяның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

**1.19.** 56 статьяның сигезенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

**2.** Әлеге карарның 1.2, 1.3., 1.13 һәм 1.14 пунктлары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

**3.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 23 октябрендәге 308 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәнең 39 статьясының 2 пунктының, 54 статьясының 3 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә) 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга.

**4.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов